Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN

УНИВЕРСИТЕТ

№ 7 (20)

15 март 2012 ел

## • Ике авыз сүз

Казан федераль университеты ректоры Илшат Гафуров җитәкчелегендәге делегациянең Сингапурга визиты дәвам итә. Визит кысаларында Сингапурның фәнни һәм мәгариф үзәкләре белән танышу, чит ил коллегаларыннан квалификацияне арттыру тәҗрибәсен алу тормышка ашырылачак.

1960-1970 елларда биредә белем бирү системасы зур үзгәрешләр кичерә. Һәр мәктәптә инглиз теле мәҗбүри укытыла башлый, югары уку йортларында инглизчә белем алалар, студентлар дөньяның иң алдынгы уку йортларында стажировка үтә.

11 март көнне Сингапурның квалификацияне арттыру буенча эшләүче укытучылар профсоюзы белән очрашу узды. Генераль директор Майк Тируман һәм КФУның Педагогика һәм психология институты директоры Айдар Кәлимуллин хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куйды. Икенче көнне делегация Дәүләт хезмәте колледжы эшчәнлеге белән таныштЫ. Шулай ук үзара килешү Меморандумына кул куелды. Ректор Илшат Гафуров Сингапур укытучыларын дәүләт хезмәткәрләре һәм MBA программасын тыңлаучылар өчен курсларда укырга чакырды. Шулай ук бу көнне «Биополис» технопаркына экскурсия оештырылды. 13 март көнне колледжда профессор Уинстон Тан «Сингапурда дәүләт идарәсе принциплары» дип аталган лекция укыды. КФУ хезмәткәрләре Сингапурның Милли университетында да булды. КФУ вәкилләре өчен университет, инфраструктур үсеш турында презентация тәкъдим ителде. Делегация Ли Куан Ю Дәүләт сәясәте мәктәбе белән дә таныштЫ. Очрашу барышында укытучыларның MBA программасында һәм дәүләт хезмәткәрләрен яңадан әзерләүдә катнашуы турында да килешенде.

• • • •

2011 елның 24 ноябрендә Мәскәү дәүләт университеты белән Казан (Идел буе) федераль университеты арасында хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә кул куелган иде. Ул фәнни, мәгариф һәм мәдәни якны үстерүгә басым ясый. Шулай ук бик күп уртак проектларны тормышка ашыру күздә тотыла. Радиоастрономик юнәлешне җәелдерү кысаларында КФУ һәм МДУ хезмәткәрләре Бад Котцинг (Германия) шәһәрендә узган халыкара фәнни конференциядә катнашты. Алар тәкъдим иткән уртак доклад халыкара фәнни элитада зур кызыксыну уятты. 1 март көнне Россия делегациясенең зур антенналар җитештерә торган корпорациясе белән берлектә махсус утырышы узды. 2 март көнне конференциянең чираттагы утырышында Ветзель фундаменталь геодезик обсерваториясендә андагы җиһазлар белән таныштылар. 3 март көнне Мюнхенда узган очрашу барышында Россия Фәннәр Академиясе академигы, Астрофизика институты директоры, профессор Р.Сюняев һәм профессор Н.Сәхибуллин 3-7 сентябрьдә астрофизика буенча халыкара фәнни конференцияне КФУда уздыру мәсьәләсен күтәрде. Чарада барлыгы 150 галим, шуларның 70 е чит илдән катнашыр дип көтелә.

• • • •

Халыкара хатын-кызлар көне уңаеннан 7 март көнне КФУ тарихы музеенда Ольга Панфутованың «Автор курчагы» исемле күргәзмәсе ачылды. Биредә әкият персонажларын да, бюрократның җыелма образларын да, милли костюмлы курчакларны да күрергә мөмкин. Автор сүзләренә караганда, алар барсы да кул астындагы материаллардан, лоскутлардан эшләнгән. Ольга Панфутова курчакларын балалар белән чагыштыра, һәркайсы йөрәгенә якын. «Алар миңа рәхәтлек китерә, әгәр сезгә дә күңелле минутлар бүләк итә алам икән, мин бик бәхетле», – ди. Курчаклар экспозициясе бер ай дәвамында сөендереп торачак. Рәхим итегез!

• • • •

Татарстан Республикасы төзүчелек комплексы белгечләренең инженерия-геологик тикшеренүләр юнәлешендә белемен күтәрү буенча университетыбызда яңа программа старт алды. «Инженерия-геологик тикшеренүләр вакытында һәм кыр яки лаборатория шартларында туфракның физик-механик үзенчәлекләрен билгеләүдә заманча методлар» дип аталган курсларга ТР ның 5 эре оешмасыннан белгечләр килде. Катнашучылар Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының техник яктан заманча югары дәрәҗәдә җиһазланган булуын искәртте.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Эльмира Сафина фотосы

# Яз килде... «Студентлар язы»!!!

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Җиһанда яз! Кояш та елмаеп карый, вакыт-вакыт кошлар сайравы ишетелеп куя. Тиздән тирә-як тагын да ямьләнер, яшеллек хөкем сөрер! Ялгыша, дисезме мине?! Ә-ә-ә-ә, имеш, салкын, кар-буран, ачы җил, дисез инде?! Менә сез ул ялгышасыз... Бездә – КФУда чын ямьле яз!!! «Студентлар язы»!!!

КФУда XIX «Студентлар язы – 2012» фестиваленә дә старт бирелде. «УНИКС» концертлар залында 18:30 да уза торган сайлап алу концертлары 10 көнгә сузылачак. 9 март көнне беренче булып А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты һәм Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты чыгыш ясады. Шулай ук Икътисад һәм финанс институты, Экология һәм география институты, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты, журналистика һәм социология факультеты, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар Югары мәктәбе тамашачыларны сөендерергә өлгерде инде.

14 март көнне фәлсәфә факультеты, биология һәм туфракны өйрәнү факультеты студентлары үз талантларын күрсәтте. Бүген Яшел Үзән филиалы, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты көч сынаша. 16 март көнне Филология һәм сәнгать институты осталары сәхнә тотачак. 17 март көнне исә Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты һәм юридик факультет тәкъдим иткән чыгышларны карап булачак. 19 мартта сәхнә түрендә Педагогика һәм психология институты белән Тарих институты йолдызлары балкыячак. Фестивальнең сайлап алу турларын Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты һәм Физика институты тәгәлләячәк. 22 мартта – Яр Чаллы, ә 11 апрельдә Алабуга филиалында шулай ук сайлап алу турлары үтәчәк.

Жюри рәисе, сәнгать һәм дөнья мәдәнияте теориясе кафедрасы мөдире, педагогика фәннәре докторы, профессор Зилия Явгильдина, студентларның чыгышларын бик югары бәяләп: «Һәркөнне талантлы студентларны, аларның иҗади потенциалын күреп сокланабыз. Студентлар тәкъдим иткән чыгышларның жанр, стиль төрлелеге шаккатыра. Фестивальнең югары дәрәҗәдә оештырылган, номерларның бик яхшы уйланып эшләнгәнлегеннән ассызыкларга кирәк.Һәркайсыүзенеңиндивидуальлеге һәм уникальлеге белән истә калачак», – диде. Талантлар арасыннан сайлап алынган иң-иңнәрне 25 апрельдә узачак фестивальнең гала-концертында күреп булачак.

## • Халыкара багланышлар

# Дуслык җепләре

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

12-13 март көннәрендә Казан федераль университетында Һиндстан көннәре узды. Аның кысаларында матур чаралар үткәрелде.

Һиндстан илчесе Аджай Малхотра җитәкчелегендәге делегация составындагы Илчелекнең хәрби һава көчләре атташесы Викрам Сингх, Илче ярдәмчесе Прит Пол Сингх һәм Илчелекнең Мәдәни үзәге директоры урынбасары Санджай Веди белән узган очрашуда тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов КФУ тарихы, аның бүгенге эшчәнлеге, киләчәккә планнар турында сөйләде, атаклы шәхесләре белән таныштырды. Шулай ук Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты турында тулы мәгълүмат бирелде.

**Ахыры 2нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

● Иҗат үре

# Яшьлек кебек кадерле...

**Ильмира КАМАЕВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты



Студент чагында адәм баласы үзен һәр өлкәдә булмаса да, күп яктан сынап карарга омтыла. Университетыбызда эшләп килә торган төрле түгәрәкләр, иҗат берләшмәләре студентларны һәр яктан үстерүдә зур роль уйный дисәк, ялгыш булмас. Шундый иҗат берләшмәләренең берсе быел үзенең 45 еллык юбилеен билгеләп үтә. Сүзебез Казан университетының Татар хоры турында.

Хор 1967 елда оеша, төп максаты - милләтебез өчен файдалы, гармонияле, зыялы шәхесләр тәрбияләү. Аның җитәкчесе - Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллин.

Ирнис Әхмәдулла улы Рәхимуллин 1942 елның 3 февралендә Казан каласында эшчеләр гаиләсендә туа. 1958-1962 елларда Казан музыка училищесында, соңрак Казан дәүләт консерваториясендә белем ала. 1970 елдан алып 1985 елга кадәр Казан консерваториясенең хор дирижерлыгы кафедрасында укыта, 1975 елдан М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында хормейстер булып эшли. Үз белгечлеге буенча иҗат эшчәнлеген унсигез яшеннән үк башлап, 1960 елда үзешчән хорга җитәкчелек итүгә алына. 1967 елдан бүгенге көнгәчә ул Казан университетында Татар халык хорын җитәкли. 1976 елда хор «Халык коллективы» дигән исемгә лаек була.

И.Рәхимуллин - гомеренең дүрт дистәдән артык елын хор сәнгатенә багышлаган кабатланмас шәхес. Казан университетының йөзләгән сәләтле егет-кызлары Ирнис Рәхимуллин мәктәбен уздылар. Бу - халык җырына тирән мәхәббәт мәктәбе, татар композиторларының тирән мәгънәле аһәңле җырларының асылына төшенү мәктәбе, студентларның музыкаль табигатен ачып, аларга канат кую мәктәбе. Ирнис Рәхимуллин хорында җырлаганнар студент елларын иң якты, иң күңелле сәхифә буларак искә ала.

Җырлап яшәүче бу студентлардан зур шәхесләр үсеп чыга: шагыйрьләр дә, җырчылар да, радио һәм телевидение эшлеклеләре, газета-журнал мөхәррирләре, мәгариф бүлеге мөдирләре һ.б. Хор мәктәбен узган егетләр-кызлар арасында доцентлар һәм профессорлар, фән кандидатлары һәм докторлары да байтак. Татар хорында җырлаган еллар барчасына яшьлекләре кебек кадерле! Республиканың радио һәм телевидение үзәк фондында хорның язмалары саклана. Аның үз солистлары һәм «Былбыл» вокаль ансамбле бар. Университет күләмендә уздырыла торган бер генә концерт-бәйгедә Татар хоры катнашыннан башка узмый. Хор коллективы - «Ягымлы яз», «Студентлар язы», «Милли хәзинә» һ.б. кебек иҗат бәйгеләре җиңүчесе. Хорга йөрүче студентлар һәрдаим орган, симфония концертларына, Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышларына, Г.Камал исемендәге драма театрына, Опера һәм балет театрына сәяхәт кылып, фикер офыкларын киңәйтәләр.

Татар хоры коллективы өчен 2012 ел аеруча истәлекле вакыйгаларга бай. Беренчедән, коллективның 45 еллык юбилее булса, икенчедән, алыштыргысыз талантлы җитәкче Ирнис абыйның олуг юбилее. Форсаттан файдаланып, хор коллективы исеменнән хөрмәтле Ирнис абыйны әлеге бәйрәме белән тәбрик итәбез. Мин аны диңгездәге корабның капитаны дияр идем. Ул һәрберебезгә иҗади якын килеп, безне бер йодрыкка туплый. Барысы өчен дә рәхмәт Сезгә, Ирнис абый! Коллективның уңышларында Сезнең өлеш чиксез зур. Тән сихәтлеге, күңел көрлеге, тормыш иптәшегез Венера апа белән бәхетле гомер телибез.

● Мөнбәр

# Чираттагы Гран-при

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Бүген бездә кунакта татар филологиясе бүлегенең V курс студенты, бүлекнең студентлар деканы Лилия Нурова.



***– Лилия, сиңа иң беренче соравым шундый: КФУның, алай гына да түгел, Татарстанның башка студентларыннан нәрсә белән аерыласың?***

– Мин үземне башка студентлардан аерылып торамдыр дип уйламыйм. Гап-гади студент, башкалар кебек үк укыйм, лекцияләр язам, зачёт-имтиханнар тапшырам. Миңа да, башка студентлар кебек үк, вакыт һәм йокы җитми. Ә болай бер үзенчәлегем бар: максат куйсам, шуңа ирешмичә тынычлана алмыйм.

***– Синең уңышларың турында ишеттек, газета укучылар белән дә бүлешсәң иде.***

– Әйе, чыннан да узган елның ахыры һәм бу елның башы уңышларга бай булды, күз тимәсен. Узган ел ахырында «КФУ ның ел студенты – 2011» конкурсында лауреат, Казан шәһәре Мэры стипендиясенә лаек булсам, әле күптән түгел генә Уфа шәһәрендә үткән «Ана теле – 2012» IV региональ студентлар конкурсында Гран-при яуладым. (Конкурс турында Интернеттан укып, мин монда катнашырга тиеш, дигән үзмаксат куйган идем). Бу педагогик осталыкны сынау бәйгесе иде. Ике көн дәвамында алты шәһәрдән килгән тугыз булачак татар теле укытучысы үз осталыкларыбызны сынадык. Конкурс берничә этаптан торды. Иң башта Уфа шәһәренә үз портфолиомны җибәрдем. Чакыру хаты килгәч, алдагы этапларга әзерләнә башладым. I конкурс – визитка, үзең һәм үзеңнең югары уку йортың белән таныштыру; II – педагогик эссены яклау, III – иҗади конкурс, IV – Уфа шәһәре мәктәпләрендә дәресләр үткәрү булды.

***– Әзерләнү ничек үтте, кыенлыклар тумадымы?***

– Нинди генә конкурс булмасын, әзерләнү җиңел булмый инде. Чөнки, иң беренче чиратта, үзең, үз бүлегең, уку йортың өчен җаваплылык тоясың. Сиңа ышанган кешеләрнең өметен акларга кирәк. Ә, икенчедән, конкурс булгач, иҗади якын килергә кирәк, башкалардан аерылып торасы килә... Кыенлыклар вакыт җитмәү белән генә бәйле. Калганнары бар да уңай: укытучылардан киңәш сорап барсам, кире какмадылар. Аерып әйтсәң, җитәкчем Роза Асылгәрәеваның ярдәме бик зур булды.

***– Ә үзеңнең укытучы һөнәренә карашың?***

– Укытучы һөнәренә карашым уңай. Ничек кенә булмасын, ул бик популяр дип уйлыйм. Барысы да укытучының үзеннән тора. Үзеңә тәнкыйть белән карап, заманнан артта калмый эшләсәң, укытсаң, укучылар белән дә, җитәкчеләр белән дә кыенлыклар булмыйдыр, дип уйлыйм.

***– Биш ел дәвамында син үзеңне талантлы студент, оста оештыручы, инде менә хәзер оста укытучы итеп тә таныттың, ә киләчәгеңне ничек күзаллыйсың?***

– Киләчәк турында планнарны әлегә ачык кына әйтәсе килми, өмет-хыяллар бик зур. Әлегә алар сер булып калсын. Иң мөһиме, V курсны уңышлы гына тәмамлап, диплом алсым килә.

● Сезне бездә көтәләр

# Үзебездә һәм читкә чыгып

**Рамил ХАННАНОВ**

Казан федераль университеты республикада гына түгел, Идел буе төбәгендә, гомумән, ил күләмендә абруйлы урын тота. Белем һәм тәрбия бирү, фән белән шөгыльләнү, иҗади үсеш, җәмгыятькә файдалы белгеч әзерләү һ.б. иң югары дәрәҗәгә җиткерелгән.

Мәктәп укучылары, аларның әти-әниләре, укытучылар, урта һәм махсус белем бирү учреждениеләре җитәкчеләрен борчыган сораулар да читтә калмый - алар һәрвакыт игътибар үзәгендә. Шуны аңлаган хәлдә, университетның төрле бүлек галим-мөгаллимнәре даими рәвештә абитуриентлар белән эшләүне дәвам итә.

Экология һәм география институтының географик һәм экологик белем бирү бүлеге вәкилләре әле күптән түгел генә Н.Савин исемендәге V халыкара фәнни-гамәли конференциядә булып кайттылар. Бик күп укучыларны һәм студентларны берләштергән әлеге чара Кукмара районының бай тарихлы Лубян авылында - урман хуҗалыгы техникумында үтте. Конференциядә география һәм геоэкология; экология һәм туган якны өйрәнү; сәламәтлек һәм медицина; филология кебек секцияләр эшләде. Катнашучылар арасында Татарстаннан гына түгел, Удмуртия Республикасы, Киров өлкәсеннән килгән вәкилләр дә байтак иде.

Конференциянең йомгаклау өлешендә географик һәм экологик белем бирү бүлеге укытучылары, V курс студентлары уку йортыбыз турында мәгълүмат җиткерде, презентация күрсәтте. Шулай ук төрле белем бирү юнәлешләре, кабул итү тәртибе, кызыклы студент тормышына бәйле сорауларга да биредә катнашучылар җавапсыз калмады.

11 март көнне исә - Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтында, ә 12 март фәлсәфә факультетында Ачык ишекләр көне үтте. Биредә күбрәк Казан укучылары, мәктәп укытучылары һәм җитәкчеләре катнашты. Әле күптән түгел генә фәлсәфә факультеты вәкилләре Аксубай районы укучылары белән очрашып кайткан иде.

Исегезгә төшерәбез: Казан федераль университетының гомуми Ачык ишекләр көне 26 февральдә үткән иде. Чираттагысы 30 март көнне узачак.

● Халыкара багланышлар

# Дуслык җепләре

**Башы 1нче биттә.**

Очрашу барышында күтәрелгән төп мәсьәлә уңай хәл ителде. КФУ базасында Һиндстан үзәген ачу идеясен илче хуплап, үзе дә ярдәм итеп торачагын, Һиндстан турында китаплар бүләк итәчәген әйтте. Татарстан халкы - Һиндстан, ә алар Татар иле, Казан турында белергә тиеш. Үзәкне Һиндстаннан җибәрелгән белгеч җитәкләячәк.

Шулай ук бу көнне «Аңлашу турында»гы ике меморандумга кул куелды. Беренчесе - Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты, Татарстан Республикасы һәм Һиндстанның Элемтәләрне үстерү мәдәни үзәге, икенчесе шул ук институт һәм Россия Федерациясендә Һиндстан илчелегенең Джавахарлала Неру исемендәге мәдәни үзәк арасында.

Чараның рәсми өлешеннән соң Аджай Малхотра, аның тормыш иптәше Ира Малхотра һәм кунаклар өчен университет тарихы музее буенча экскурсия оештырылды. Илче очрашудан бик канәгать калды һәм истәлек итеп Мактаулы кунаклар китабында: «Горурланырлык тарихы булган Казан федераль университетын күреп шаккаттым. Һиндстан белән элемтәләрегез ныгыр дип ышанам», - дигән теләкләрен калдырды.

Бу көнне дуслык йөзеннән Филология һәм сәнгать институтының Актлар залында «Mamata Shankar Dance Company» һинд бию ансамбле «Язгы бәйрәм» исемле бүләк ясады. Һинд язучысы, шагыйрь, композитор, рәссам һәм җәмәгать эшлеклесе Рабиндранат Тагор кешенең рухи үсешенә зур игътибар бирә. Аның фикеренчә, аң һәм җан бергә, табигатькә якын булганда гына югарылыкка менә ала. Шушы фәлсәфәгә нигезләнеп, Тагор Сантиникетан исемле кечкенә генә шәһәрдә, ел фасыллары үзгәргән саен, фестиваль уздыра. Анда агач утырту, беренче яңгырны сәламләү, көзгә, кышка, җәй айларына багышланган концертлар уза. Һинд ансамбле тәкъдим иткән кичә дә әлеге фестиваль традицияләренә нигезләнеп эшләнгән иде.

Кечкенә галимнәр

# «Кояш» темасын өйрәнгәндә

**Җәүдәт ХӨСӘЕНОВ,**
педагогика фәннәре докторы, табигать фәннәрен һәм географияне укыту теориясе һәм методикасы кафедрасы профессоры





Минем педагогик стажым бик зур, ул 44 ел тәшкил итә. Шул дәвер эчендә миңа мәктәптә бик озак еллар табигать белеме, география һәм соңыннан экология фәннәрен укытырга туры килде. Яшьрәк чакта туган авылым - Чүпрәле районы Кече Чынлы урта мәктәбендә V сыйныф балаларына табигать белеме фәнен укыттым. Әле дә хәтеремдә: «Кояш» дигән теманы өйрәнәбез. Дәрестә кояшның физик халәтен сөйләгәннән соң, укучыларга шундый сорау бирдем: «Балалар, уйлап карыйк әле: кояшның җир шары өчен нинди әһәмияте бар соң?» Шул вакыт бер укучы кул күтәрде дә: «Абый, кояшның файдасы бик зур аның, ул безгә төшке ашны кайчан ашарга кирәклеген күрсәтеп тора», - диде. Билгеле, сыйныфтагы укучыларга да, үземә дә аның җавабы ошады. Шул чакта барыбызга да күңелле булган иде. Бу хатирәләрне бүген дә елмаеп, эчкерсез бер җылылык белән искә алам...

Очрашулар

# Сәбәп - «Ком сәгате»

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

Күптән түгел татар филологиясе бүлегендә язучы-сатирик Камил Кәримов белән очрашу узды. Язмамны гадәти итеп кенә башласам да, әлеге очрашу башкалары кебек түгел иде. Бу сәгать ярым вакытны без ачык дәрес дип тә, җанлы әңгәмә яисә фәнни конференция дип тә атый алабыз.

«Быел Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге премиясенә тәкъдим ителгән «Ком сәгате» дилогиясенең язмышы бәхетле булды: әсәрнең төп герое Фазылны халык яратты, башка геройларның язмышлары да укучыны битараф калдырмады», – дип яза Марат Закир. Очрашуның да төп сәбәбе нәкъ менә «Ком сәгате» иде. Уку программасына кертелгән әлеге әсәрне бик ныклап өйрәнгән иде V курс студентлары. Бу көнне студентлар һәм аларның укытучылары Фәридә Хәсәнова, Луиза Җамалиевалар әсәрне анализлап, автор бөтенләй уйламаган юнәлешкә китереп чыгардылар. «Әсәрне укып, соңгы битен япкач, мин үзем өчен К.Кәримов иҗаты буенча яңалык ачтым. Язучының бу дилогиясе халык авыз иҗаты жанрларының трансформацияләнгән формада бүгенге көндә халык телендә, әдәбиятта яшәешен күрсәтүче иң яхшы мисал икән. Әйтергә кирәк, халык иҗаты буенча энциклопедик сүзлек характерындагы мисал. Сүзлеге хәрефләр тәртибе буенча түгел, ә кеше исемнәренә бәйле төзелгән», – дип сүзен башлады Л.Җамалиева. Шул рәвешле, ул 80 нче еллардагы су бораулаучылар романтикасы, табигать, авыл, милләт язмышына үрелеп барган «Ком сәгате» кебек дилогияне фольклорга нигезләнеп анализлап та чыкты. Мондый чишелешне әсәрне укып-өйрәнгән студентлар гына түгел, автор үзе дә көтмәгән иде булса кирәк. Студентлар да югалып калмадылар: үзләренчә анализлап, әсәргә, авторның шәхси тормышына кагылышлы сораулар яудырып кына тордылар. Ә җаваплар кызыклы һәм үткен телле иде, нәкъ тә менә сатира, юмор остасы буларак таныш Камил Кәримовча.

Бүлек җитәкчесе Флёра Сәйфулина бик җанлы чыгыш ясады. «Сезне дә Тукай бүләге иясе буларак бу китапта күрергә теләр идек», – дигән ишарә белән ул К.Кәримовка әлеге премия лауреатлары тупланган китап бүләк итте.

Очрашуны Татарстан язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев йомгаклады, К.Кәримов һәм аның әсәрләре турында бары уңай фикерләр генә әйтте. «Мин Казанда эшләп калуым белән дә нәкъ менә аңа бурычлы. Ул миңа үзенең эш урынын биреп, башкалада калдырмаса, бүгенге көндә кая булыр идем икән?!.» – дип искәртте.

Язучының Шәледә үткән иҗат кичәсендә бер авылдашы кебек безгә дә: «Нигә сез безнең Камилгә һаман Тукай премиясен бирмисез ул?» – диясе генә кала...

Премьера

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

# Беренче мәхәббәт

1 март – язның беренче көнендә университетның «Мизгел» яшьләр театры премьера тәкъдим итте.

Күңел саф һәм матур хисләр, күтәренке кәеф таләп итә торган чорга кердек. Күптән күрешмәгән дуслар белән очрашасы, хәл-әхвәлләрне сорашасы килә. Үзеңне укыткан укытучылар да сагындырган. «Мизгел» театрына шуның өчен дә рәхмәтле мин, тәмам эштән арган башны ял иттерергә, студент елларыннан бирле күрешмәгән төркемдәшләр, хәтта «беренче мәхәббәт» белән очрашырга мөмкинлек тудыра ул.

Ә аның турында ишетмәгән, алар куйган спектакльне карамаган кеше бар микән? Бу юлы да зал шыгрым тулы иде. Студентлардан тыш татар теле курсларына йөрүчеләр, уку йортын күптән тәмамлаганнар да, әби-апалар да күп иде. Елдагыча күршеләребез – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының хөрмәтле артистлары да кергән иде.

Театрның режиссёры Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Марсель абый Җаббаров Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» драмасын һәм рольләрне башкаручыларны сайлап ялгышмаган. Беренче пәрдәнең башында Тәлгать (Илнар Галиәхмәтов) белән Рәхилә (Венера Макова) таныша. Беренче диалогларда ук геройларга күпмедер дәрәҗәдә бәя бирергә, спектакльнең нинди тонда үтәсен чамаларга була. Рәхилә – чая, шук, төрттерергә яратучы, иркә, горур кыз, ә Тәлгатьнең төпле, үз сүзендә нык торучы, шулай ук горур егет икәнен күрәбез. Егет Рәхиләнең әтисе Сәлимгә (Алмаз Молдашев) вафат булган әнисенең хатын тапшырырга килә. Хатта ни язылганын Рәхиләнең генә түгел, тамашачының да бик беләсе килә, ләкин Тәлгать ирек бирми. Чая кыз егетне үзләрендә яшәргә чакыра, мәктәп директоры булып эшләүче Сәлим дә бик теләп ризалаша. Аңлашыла да: Тәлгать аның улы булып чыга. Хатыны Камилә (Лениза Гатауллина) бу хәлләргә бер дә риза булмый, ләкин Рәхилә аны да күндерә.

Нурсанә (Энҗе Сәетзадә) белән Әпсәләм (Илназ Баһ) ярдәмче сюжет тудыруда катнашалар. Нурсанә – Рәхиләнең бик якын дусты, үзеннән яшьрәк Әпсәләмдә кияүдә. Икесе дә шат күңелле, җыр-моңга гашыйк гаилә, колхозда эшлиләр.

Госман (Ленар Хамматов) – Рәхиләгә гашыйк укытучы, аңа өйләнергә җыенып йөри. Булачак хатынын югары белемле итү турында уйлый. Рәхиләнең Госманны яратмаганы әллә каян сизелеп тора, ләкин ул да шәһәрдә яшәү, белем алу турында хыяллана.

Нәтиҗәдә тамашачыга бертуганнар буларак билгеле Рәхилә белән Тәлгать арасында чын мәхәббәт хисләре уяна. Авыл тормышын, җирне яратучы Тәлгать көтүче булып эшкә урнаша, хәтта Рәхилә дә авылда кала. Көнләшүдән төрле начарлыклар эшләргә әзер Госман Тәлгатьнең Сәлим улы икәнен әйтә. Ике яшь йөрәк газап утларында яна башлый. Ләкин кискен конфликт бөтенләй башка борылыш ала: кызның балалар йортыннан алынганлыгы ачыклана. Тәлгать китәргә җыена, тик Рәхиләнең соңгы сүзләре моның алай булмаячагын әйтә: «Җибәрмим, беркая да җибәрмим!.. Киләчәгемне мин беренче мәртәбә шулай ачык күрәм. Син ачтың аны... Тормышның бу кадәр матур икәнлеген белми идем әле мин. Әнә шул камышларны да, менә бу кәкре каенны да, әнә андагы көтүеңне дә – барысын, барысын да яратам! Ишетәсеңме, яратам! Беренче мәртәбә!» Героиняның әлеге сүзләре алар киләчәгенең нинди буласын күзалларга ярдәм итә. Вакытлар үтү белән, Тәлгать тә атасын кичерер, тормыш та дөньяның матурлыгына, мәхәббәтнең бөеклегенә сокланып үтәр төсле тоела.

Госман ролен башкарган Ленар Хамматов, I курс студенты булуга карамастан, сәхнәдә үзен бик иркен тотты. Артистлар, гадәттә, уңай геройга караганда, тискәре рольне башкару күпкә авыррак, диләр. Ленар Госманның бөтен якларын да ачып бирә алды. V һәм IV курс студентлары Илнар белән Венера тамашачыга яхшы таныш, ләкин бу спектакль барышында без аларның яңа якларын ачтык. Венера, оста итеп уйнаудан тыш, бик моңлы җырлый да әле. Алмаз Молдашев, Лениза Гатауллина, Энҗе Сәетзадә – остарып беткән артистлар, зур сәхнәләрдә чыгыш ясарлык талантлары, тәҗрибәләре бар. Спектакль барышында яңгыраган җырларның авторы, җырчы, баянчы, Әпсәләм ролен башкарган Илназ Баһ – уку йортыбызның горурлыгы.

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Нәҗибә Ихсанова, яшь артистларның осталыгын ассызыклап: «Филология һәм сәнгать институтының төп максаты – студентларга белем бирү. Биредә, белемне театр белән аралаштырып, милләтне үстерү өчен, галәмәт зур эш эшлиләр. Марсель Җаббаровка егетлеге өчен зур рәхмәт. Театрдан киткәч, кызгандым, бик шәп артист иде. Ләкин ул үзен шушында тапты, миңа калса, беркайчан да югалмас. Җитди әсәрләр алып, җитди характерлар тудырып, яңа талантлар ачар, безне куандырыр дип уйлыйм», – диде.

Театрның эшчәнлеген тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов бик югары бәяләде һәм КФУ ректоры Илшат Гафуровның Рәхмәт хатын тапшырды. Институт директоры Рәдиф Җамалетдинов та, мизгеллеләргә алга таба зур уңышлар теләп: «Институтны театрдан башка күз алдына китермим. 15 ел буе сезне яңа яклардан ачабыз. Тормышчан әсәрләр куюыгыз өчен зур рәхмәт», – диде.

Эшнең нәтиҗәсе – күз алдында. Зал көчле алкышларга күмелде, артистлар чәчәк бәйләмнәренә төренде. Ә алар өчен шуннан кадерлерәк тагын нинди бүләк бар икән соң?!



## Илһам канатында



**Ленар Гәбделфәрт улы ХАММАТОВ** 1993 елның 26 октябрендә Арча районы Хәсәншәех авылында туган. Бүгенге көндә татар филологиясе бүлегенен I курсында белем ала. Шигърият һәм проза өлкәсендә үзен сыный, тирән фикерле, мәгънәле публицистик язмалары белән аерылып тора. Сезгә кызыклы мәкаләләре аша таныш яшь иҗатчының кайбер шигырьләрен тәкъдим итәбез.

***

*Якташ, диеп әйтер идем – якташ түгел,*
*Дустым, диеп әйтсәм әгәр, синең күңел*
*Кабул итмәс мине, рәнҗеттем бит,*
*Рәнҗетте бит ялгыш кына әйткән сүзем.*

*Сүзләр бик күп, үлчәп әйтер вакыт җитте,*
*Укны аттың, ә соң ул ук очты китте.*
*Куар идем әйткән сүземнең артыннан,*
*Мөмкин булса, хәер, тизлеге бик көчле.*

*Бәлки,газап утында янасыңдыр бүген,*
*Ничектер моңсу да, күңелле дә бу көн.*
*Барсы да кушылган, әйтерсең лә томан,*
*Томан түгел шул бу, бары тик бер ялган.*

***

*Килеп кердем монда ятим булып,*
*Үги булып яшим бүген дә.*
*Сөякләрне кемдер кимерә, ди –*
*Арткан икән ерткыч бу илдә.*

*Берсе әйтә: «Миндә бүре каны,*
*Ярты-йортыларга ау башлыйм».*
*Сөяк каты түгел, кил бирегә –*
*Иң беренче ризык мин булыйм.*

*Катлам булгач, була торган хәл бу –*
*Дүртенче сорт түгел, бишенче.*
*Гибрид, диеп әйтә кайберләре,*
*Имгәк, диеп дәшә берсесе.*

*«Йөрмә әле, зинһар, син, энекәш,*
*Аяк асларында буталып.*
*Яратмыйм мин план белән туып,*
*Йөргәннәрне янда, сан булып.*

*Бүленмәгән саннар кирәк түгел,*
*Бездә аны һичкем хупламый.*
*Кирәк булса, алып телгәлим лә,*
*Ләкин тормыш үзе тураклый.*

*Бүреләргә аучы табылганга,*
*Бал кортына инде әйләнеп,*
*Чагып әле генә киткән иде,*
*Тагын килде менә, бәйләнеп.*

*Сөйләп китсәм, әле башы гына,*
*Кемгә кирәк кеше кайгысы?!*
*Турыгадыр сезнең юлларыгыз...*
*Ә соң минем юллар кайсысы?»*

*Килеп кердем монда ятим булып,*
*Үги булып яшим бүген дә.*
*Тыныч үтсен бу көн, ардым инде,*
*Җитәр, дуслар, җитәр бүгенгә...*

### Тәүбә

*Иелгән башны кылыч кисми, диләр.*
*Башны иям синең алдыңда.*
*Атлаганда алга куркып торам –*
*Тәүбә ишекләре каршында.*

*Йөгереп килеп,шушы ишекләрне*
*Куллар канаганчы шакыйсы...*
*Гөнаһларның монда кертмәгәне,*
*Әйтегезче миңа – кайсысы?*

***

*Шигъри юллар, кая илтә алар?*
*Кагыйдәсе аның соң кайда?*
*Кемгә карап үзгәрә бу дөнья?*
*Чыктык чиктән – соңгы бусага.*

*Яшь кеше мин, картаясы килми!*
*Үтә яшьлек, санаулы көн кими.*

*...Бәлки, аңламам тормышның серен...*
*Тик мәгънәсен һаман эзләрмен...*
*Табармын эзләрен...*

## Сәламәтлек

# Башың авыртмасын дисәң...

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Суык көнне урамга чыккач, баш киемсез йөрүче кешеләрне күрү бер дә гаҗәп хәл түгел. Күп кенә хатын-кызлар ясаган прическаларын бозмау максатыннан, әллә нинди суыкларда да башлыкларын кимиләр. Шул ук вакытта яшьләр арасында, суыкка ияләшкән баш киләчәктә чыныгып, авыруларга бирешми, дигән фикер дә йөри. Бу күренешләрнең нәтиҗәсе бихисап хроник һ.б. җитди авырулар булуын күпләр хәтта күз алларына да китермидер.



Беренчедән, суык һава колакларга бик зур зыян сала. Каты искән җилдән, колакларның эчке өлешләре ялкынсына һәм еш кына колак сызлаулары, чигә өлешләрендә авыртулар барлыкка килергә мөмкин. Бер тапкыр каты итеп ялкынсынган ишетү органын дәвалауга бик җитди карарга кирәк. Аның киләчәктә тагын да катлауланып китү куркынычы бар.


Баш киемсез йөрүнең тагын бер нәтиҗәсе борын куышлыгы авырулары белән бәйле. Гадәттә, суыкта без салкын һаваны иснибез һәм ул, борын куышлыгында җылынып, эчкә үтә. Әгәр дә баш киемебез булмаса, бу процесс тоткарлана һәм борын суламый башлый, тамак төбендә авырту барлыкка килә. Гайморит, фронтит кебек җитди авыруларга сәбәп туа.

Еш кына баш авыртулар борчып торса, бу шулай ук баш киемеңне өйдә саклауның нәтиҗәсе икәнен белеп торырга кирәк. Башның арткы өлешендәге авырту әле җылы бүлмәгә кергәч, көчәеп, һаман саен үзен сиздереп торачак. Өлкәнәйгән саен, үзенең барлыгын әледән-әле «искәртәчәк» кенә. Башның ул өлешендә күзләр белән бәйле нервлар урнашкан, шуңа күрә күзнең начараюы да суык көндә башлыксыз йөрүдән килеп чыгарга мөмкин.

Гомумән алганда, бүрек астында «матур прическам бозыла», дип йөрүчеләр үзләренең сәламәтлекләрен куркыныч астына куялар. Уйлап карасаң, башына җыйнак кына итеп киеп куйган баш киемле кешеләр, кызарып беткән колакборынлы, җилдә тузгыган чәчләрдән күпкә матуррак та, сәламәтрәк тә күренә бит! Һәрберебезнең саулыгы үз кулында икәнне беркайчан да онытмасак иде!

## Дөнья үзебезнеке

# Ике йөзенче кочаклашу



**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

*Тән төсе саргая башлаган, провод һәм трубкалар белән уратылган әтием интенсив терапия палатасында ята иде. Ул һәрвакыт тыгыз,тулы гәүдәле кеше,ә хәзер 30 фунттан артык авырлыгын югалткан хәлдә. Аңа «ашказаны асты бизендә яман шеш»нең иң авыр формасы дигән диагноз куйдылар. Табиблар булдыра алганның барысын да эшләде,әтиебезнең өч-алты ай яшисе калганын да әйтте. Бу авыру нурландыруга да,химиятерапиягә дә бирешми,шуңа күрә ышаныч бик аз иде.*

*Берничә көннән әтием янына килгәндә,ул караватында утыра иде. Мин аңа: «Әти,синең белән мондый хәл килеп чыгуына бик борчылам. Моңа кадәр,сине өзелеп яратсам да, читләшебрәк йөргәнемне аңладым», - дидем. Мин аны кочакларга дип иелдем,тик аның җилкәсе һәм куллары җыерылып куйды. - «Ярар инде,әти,минем сине чынлап та кочаклыйсым килә».*

*Берара ул исе киткән хәлдә кебек булды. Безнең гаиләдә хисләреңне белгертү дигән нәрсә юк иде. Мин кочакларга җайлы булсын өчен,аның аз гына өскәрәк утыруын үтендем, кочакламакчы булдым. Бу юлы ул тагын да ныграк җыерылды. Мин гадәтләнгән үпкәмнең тагын да ныгайганын тойдым һәм: «Ярар, кирәкмәгәч — кирәкми. Әгәр мине безнең арада булган салкынлык хәлендә калдырып китәсең килә икән,бигайбә».*

*Озак еллар буе әтиемнең тотнаклыгын һәм артык җитдилеген гаепләп: «Менә,аңа барыбер»,— дип киреләнә идем. Тик бу юлы мин кинәт кенә кочаклашуыбызның аның өчен генә түгел,минем өчен дә кирәк икәнен аңладым. Миңа теләмичә генә ачылуына да карамыйча,аның өчен ничек бочылуымны сиздерәсем килде. Үзенең табигате белән минем әти немецка охшаган. Бөтен җирдә тәртип булганны ярата,күрәсең,әти-әниләре ирләрчә булсын дип, хисләрен яшерергә өйрәткәннәр. Электән үк бер-беребезгә ят булуда аны гаепләп әйтергә җыенган сүзләремне читкә куып,яратуымны күрсәтүдә бирешмәскә булдым. Мин: «Әти, киреләнмә,кочакла мине»,— дидем һәм аңа иелдем. Әтием мине кочаклады. - «Ә хәзер тагын да ныграк кочакла. Менә шулай. Тагын бер мәртәбә,катырак кысып. Бик яхшы!»*

*Мин әтине кочакларга өйрәттем һәм ул мине хәзер инде ничектер башкачарак кысып кочаклады. Шул мизгелдә «Мин сине яратам», дигән кебегрәк халәт тойдым. Елдан-ел өйрәнелгән гадәт буенча,кул кысышып,«Саумы,хәлләр ничек?» сүзләре белән күрештек. Хәзер без икебез дә бу кыска гына мизгелнең тагын кабатлануын көтә идек. Әтинең гәүдәсе барыбер киеренке хәлдә калганлыктан,кочаклавы шыксыз һәм читенрәк иде әле. Бу кыенлык узып, хисләрен кочаклашу аша җиңел генә сиздерә алсын өчен,берничә ай кирәк булды.*

*Әтинең мине беренче булып кочаклавын теләдем,тик моңа кадәр күп мәртәбәләр үземә башлап кочакларга туры килде. Мин аны гаепләмәдем,ә ничек тә хәленә керергә тырыштым. Уйлап карасаң,ул бит гомере буена килгән гадәтен алыштыра,ә бу вакыт сорый. Безнең арада күбрәк кайгыртучанлык,ярату йөргәнлектән,мин үзебезнең барысын да дөрес эшләгәнебезне белә идем. Хәтеремдә: бер ике йөзенче кочаклашуыбызда беренче мәртәбә әтием: «Мин яратам сине»,— диде.*

*Гарольд Х.Блумфилд*




DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла